Аксубай муниципаль районы
Федоровка авыл жирлеге Советы
423050Аксубай районы,ЯңаҮзиавылы
Мәктәпурамы, 7 нчейорт

Совет Беловского сельского
поселения Аксубаевского
муниципального района
423050Аксубаевский
район,с.НовоеУзеевоулица
Школьная, д.7

Тел. (8-84344-4-08-19) ОГРН 1061665003212,
ОКПО 04306440, ИНН/КПП 1603005000/160301001
E-mail: *Belov.Aks@tatar.ru,sovet.belov@mail.ru*

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

**№2** **15.11.2024 ел**

«Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең
Федоровка поселогында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

Карар бирәм:

1. 2024 елның 25 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең Алексеевка авылы Зеленая урамы 21йорт адресы буенча Федоровка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең Федоровка поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсуслаштырылган хәрби операциягә мобилизацияләнгән, (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр) һәм аларның гаилә әгъзаларннан тыш (бергә яшәүче ата-аналар), ир белән хатын, балигъ булган балалар) 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым җыярга, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы:
   1.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.
   - Беловка авыл җирлегенең Федоровка авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.(Беловка авыл җирлегенең Федоровка торак пункты чикләрендә юлны кышкы карап тоту (юлларны кардан чистарту, запас частьләр һәм җайланмалар сатып

алу; эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

2.Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:

-су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (Федоровка авылында сууткәргеч челтәрен ремонтлау, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).

3. Җирлек торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү(Федоровка авылы өчен янгын сүндерү өчен савыт һәм аңа комплектлау әйберләре сатып алу).

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Беловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырып, түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы



И. Р. Мәхмүтов